Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кырык Садак авыл җирлегенең Рус Кырык Садагы авылында гражданнар җыены карары

16 декабрь 2021 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кырык Садак авыл җирлегенең Рус Кырык Садагы авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2022 елда Кырык Садак авыл җирлегенең Рус Кырык Садагы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- Рус Кырык Садагы авылында юлларны төзекләндерүгә юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Кырык Садак авыл җирлегенең Рус Кырык Садагы авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Кырык Садак авыл җирлеге башлыгы _________ В.Ф. Шаһиева

Халык җыены секретаре _________ Ф.Г. Миңнегалиева